# Нурчыклар

*Буа районы “Кояшкай” балалар бакчасы гәҗите*

**№10 Июнь, 2021 ел**



## 1 июнь- Балаларны яклау көне!

Җәйнең беренче көнендә, Җир шары иң матур һәм иң якты бәйрәмнәрнең берсе булган Халыкара балаларны яклау көнен билгеләп үтә. Балалар - безнең киләчәгебез! Һәр көн, һәр сәгать һәм һәр минут алар турында кайгыртырга – бу безнең девиз!

Бүгенге санда

1. Балаларны яклау көне.
2. Сабантуй
3. Музейга сәяхәт

Балаларның киләчәге матур булсын өчен тыныч, имин тормыш, яраткан туган җир, гаилә җылысы, күңелле балачак кирәк. Балалар - ул бәхет, могҗиза! Балалар – тормышыбызның бар мәгънәсе һәм илһам чыганагы. Аларның мәрхәмәтле, кешелекле һәм иң мөһиме – сәламәт булып үсүенә ата-аналар, без-балалар бакчасы, бурычлы.

Кадерле балалар, сәламәт, акыллы, белемле һәм игелекле булып үсегез! Сез - безнең киләчәгебез, якты өметебез! Һәм без зур ышаныч белән шуны әйтә алабыз: балалар шатлансын, көлсен өчен барысын да эшлибез. Бүген бөтен җирдә балалар көлүе яңгырый. Ихлас, күңелле, шаян...

Җәйге ял күңелле, кызыклы һәм онытылмаслык булачак! Җәй әле башланды гына һәм алда балаларны бик күп кызыклы, мавыктыргыч чаралар көтә.

*Иң изге теләкләр белән, балалар бакчасы җитәкчесе Э.З.Әбүзәрова*



## БАКЧАБЫЗДА ХАЛЫКАРА БАЛАЛАР ЯКЛАУ КӨНЕ







# "Котлы булсын, гөрләп торсын ямьле сабантуйлары!"



9 июнь көнне бакчабызда Сабантуй бәйрәме булып узды.

Балаларыбыз өлкәннәрдән калышмый, Сабантуй бәйрәмен “Ат чабышы” белән башлап җибәрде. Бар да кызыксынып, дулкынлану белән “атлар” ны күзләделәр, иптәшләренә көч биреп тордылар.

“Капчык сугышы”, “Аркан тартыш” ярышларында да теләп катнаштылар. Биредә көч тә, җитезлек тә сынала. “Чиләк белән су ташу”, “Капчык киеп йөгерү”, “Кашыкка йомырка салып йөгерү” уеннары да балалар өчен кызыклы булды. Алар һәрбер уенда актив катнашып, көч сынаштылар, бер-берсе өчен җан атып тордылар.



Сабантуй батыры элек-электән иң көчле, иң чыдам, иң булдыклы булып саналган: аның турында хәтта төрле такмаклар, җырлар җырлана. Шул исәптән, малайларыбыз өчен Милли Көрәш бәйгесе оештырылды.

Бәйрәмне йомгаклап, балалар татар халык биюен биеделәр. Киләсе Сабантуйларында актив катнашырга сүз бирделәр.




































# "Идел буе халык уеннары" фестивале



Бүген "Кояшкай" балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр Идел елгасы буйлап сәяхәткә киттеләр, анда аларны төрле милләт балалары сәламләделәр. Бәйрәмдә катнашучылар бик теләп чуваш,татар, мордва, башкорт һәм рус халыкларының уеннарын уйнадылар. Шулай ук һәр халык милли ризык әзерләде һәм кунакларны сыйлады. "Идел буе халык уеннары" фестивале "Халыклар дуслыгы"биюе белән тәмамланды.

















## БАКЫЙ УРМАНЧЕ МУЗЕЙ-ЙОРТЫНДА

Бакый Урманче музее белән танышу максаты белән 16 июнь көнне безнең бакчабызның зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары Кұл Черкен авылында Бакый Урманче музей - йортында булдылар. Максат: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда гражданлык-патриотик хисләр формалаштыру; балаларны үз халкының мәдәнияте һәм көнкүреше белән таныштыру, кызыксынучанлык, күзәтүчәнлек формалаштыру. Безне музей хуҗабикәсе Илдия Рифкатовна җылы каршы алды.

Музейда без борынгы бинаның гаҗәеп атмосферасына эләктек. Экскурсия ахырында балалар белән уеннар уйнадык. Балалар татар шагыйрьләренең шигырьләрен сөйләделәр. Экскурсоводны күңел белән тыңладылар. Без барыгызны да бу музейга килергә чакырабыз.











## ЧЕМОДАНДА ХАЛЫК МӘДӘНИЯТЕ

Безнең балалар бакчабызда «Чемоданда халык мәдәнияте» мобиль проекты тормышка ашырыла башлады. Бу проект агарту характерына ия һәм аның төп максаты-Идел буе халыкларының традицияләрен саклап калу һәм алар турында балалар бакчасында тәрбияләнүчеләргә, ата-аналарга һәм кунакларга сөйләү. «Чемоданда халык мәдәнияте» мобиль күргәзмәсе дүрт күчмә чемоданнан тора. Аларның һәркайсы бер милләтне күрсәтә һәм Идел буе халыкларының мәдәниятен һәм көнкүрешен чагылдыра.













# Башваткычны чиш!









| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К | Г | К | Р | С | С | О | О | Я | Н |
| Т | И | С | И | А | К | Ф | Б | А | Б |
| А | Р | А | П | К | А | О | А | Р | А |
| М | К | К | Д | Е | О | Н | Б | А | П |
| Р | А | О | Р | О | Н | П | И | Н | З |
| О | Я | К | Л | Н | Е | Т | А | Н | И |
| И | Л | Ь | А | Р | Б | Ы | Т | О | Н |
| В | И | О | Н | Л | Ь | Р | К | У | Р |
| О | О | Л | Ч | Е | Р | Г | Ы | Й | А |







Рәсемнәрдә сурәтләнгән музыка уен коралларының исемнәрен башваткычтан табыгыз. Бер сүз билгеләп куелган инде. Артып калган хәрефләрне буш шакмакларга дөрес язсагыз, музыка белән бәйле профессия килеп чыгар.

«Нурчыклар» гәҗитен гамәлгә куючы:
Татарстан Республикасы Буа шәһәренең катнаш төрдәге “Кояшкай” балалар бакчасы” муниципаль бюджет учреждениесе

Редколлегия әгъзалары:
Гиниятуллина Д.Р.

Безнең адрес:
422430, Буа шәһәре,
Арефьева урамы, 13 йорт

Тел. (843)743-13-09
E-mail: colnush-bua@mail.ru